Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№11-12 (23-24). 2011 ел, 30 декабрь. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы



**Яңа ел белән!**

## В.Н. Лихачёвны котлау



**Татарстан Дәүләт Советының КПРФ фракциясе һәм КПРФның Татарстан республика комитеты Россия Дәүләт Думасының VI чакырылыш депутаты, КПРФ фракциясе һәм халыкара мәсьәләләр буенча Комитет члены, юридик фәннәр докторы Лихачёв Василий Николаевичны чын күңелдән 60 яшьлек юбилее белән котлыйлар.**

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының социаль-экономик, иҗтимагый-политик үсешенә лаеклы өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты Лихачёв Василий Николаевичка Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

* * *

**В.Н.Лихачёв** 1952 елның 5 январенда Горький шәһәрендә туган, В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган. 1991-1995 елларда – ТР вице-президенты. 1995-1998 елларда ТР Дәүләт Советы председателе.

## КПРФның Татарстан рескомы IX пленумы

2011 елның 24 декабрендә КПРФ Татарстан региональ бүлегенең чираттагы пленумы узды. Көн кадагына куелган төп мәсьәлә – алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлар сайлау кампаниясенә йомгак ясау һәм Россия Федерациясе Президентын сайлауларга әзерлек барышында, аны үткәрүдә рескомның, җирле партия бүлекләренең, һәрбер коммунистның бурычлары билгеләнде.

Доклад белән рескомның беренче секретаре Х.Г. Миргалимов чыкты. Атап әйткәндә, ул 4 декабрь көнне узган сайлау кампаниясе йомгаклары буенча караганда, барлык шикаятьләрнең һәм сайлау законнары бозылуга бәйле булган актлар санының 100дән артып китүен, шуларның 89ы буенча ачылган эшләрнең ТР шәһәр һәм район прокуратураларында тикшерелү стадиясендә икәнлеген билгеләп үтте.

Сайлау йомгаклары буенча Казанда (Мәскәү, Авиатөзелеш, Яңа Савин район комитетлары), Чаллыда (Үзәк, Комсомол, Автозавод район комитетлары), Тәтеш, Азнакай, Зеленодольск, Чистай, Бөгелмә, Түбән Камада район комитетларының эш нәтиҗәләре яхшы гына булып чыкты, бу исә гомуми күрсәткечкә чагылыш таппы. Татарстан региональ бүлегеннән РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасына депутатлар булып В.Н. Лихачёв белән В.П. Пешков сайландылар.

Шул ук вакытта кайбер авыл районнарында нәтиҗәләр шактый түбән булды, бу сайлау кампаниясенә әзерлек барышында, аны уздырганда эшнең канәгатьләнерлек алып барылмавы турында сөйли. Бигрәк тә Әлки, Питрәч, Нурлат районнары комитетларының эш күрсәткечләре түбән булу күзәтелә.

КПРФның XIV съездында РФ Президентлыгы вазыйфаларына кандидат итеп Геннадий Андреевич Зюганов тәкъдим ителде. Хәзер партия лидерының РФ Президенты итеп сайлануына ирешү өчен, барлык Татарстан коммунистларына, җирле бүлекләргә ныклы көрәш алып барырга кирәк.

Моңа бәйле рәвештә һәм узган сайлаулар барышында ачыкланган кимчелекләрнең барысын да истә тотып, агитация эшләрен кискен арттырырга һәм көчәйтергә, участок сайлау комиссияләренә хәлиткеч тавыш бирү хокукы булган членнарны район һәм шәһәрләрдә мөмкин кадәр күбрәк кертүгә ирешү, күзәтүчеләр белән тәэмин итү, КПРФның җирле бүлекләрендә юридик хезмәт оештыру, сайлау кампаниясендә катнашучы барлык звеноларны укытуөйрәтү эшен башкарырга кирәк.

Фикер алышуларда катнаштылар: реском членнары һәм җирле бүлекләр секретарьлары В.И. Кострин, А.В. Прокофьев, В.В. Натальин, М.З. Гарифуллин, Ф.Ю. Рыбаков, Н.В. Иванов, Л.С. Ерохин, А.Ф. Агафонов, П.Г. Кудрин, Ю.Н. Петров, В.Н. Мурахов, А.С. Сәрвәретдинов, А.В. Бутурин, Р.Д. Җиһаншин, Э.В. Мадиров, Е.К. Иосипов, Р.Р. Сәлахов.

РФ Дәүләт Думасына сайланган депутатлар В.Н. Лихачёв белән В.П. Пешков, ТР Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев сайлау кампаниясе барышында алып барылган эшкә һәм 4 декабрьдә булып узган сайлаулардан соң илдә килеп туган хәлләргә үз бәяләрен бирделәр.

В.Н. Лихачёв билгеләп үткәнчә, 2007 елда Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында Татарстанда КПРФның реаль күрсәткечләре 21 процент булып, аны 6,71 процентка кадәр киметкәннәр иде. Ә 2011 елның 4 декабрендәге фальсификацияләр масштабы турында фикер йөрткәндә исә бер генә фактны китерү дә җитә. Төньяк Кавказ республикаларының берсендә сайлауларда сайлаучыларның нибары 3 проценты гына катнашкан, әмма «Бердәм Россия»нең күрсәткече анда 91 процент тәшкил итә!

Властьтагы партия рәсми тестә үзенең политик курсын, идеологиясен әле дә булса ачыклап әйтмәде. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр, капитализмның примитив лозунгына ияреп, түбән тәгәри: хокук нормаларын санга сугып торма, баюыңны бел! Шул ук вакытта илдәге халыкның 50 проценты диярлек ярымкол хәлендә, аларның статусы – киләчәге юк кешеләр.

Чыгышының ахырында В.Н. Лихачёв Казанга килер алдыннан үзенең Г.А. Зюганов белән очрашуын әйтеп үтте. Ул КПРФ лидерының республика партактивына сәламен һәм киңәшләрен ирештерде: һич кичекмәстән РФ Президентын сайлауларга әзерлек эшләрен башлап җибәрергә!

В.В. Пешков киңәшмәдә катнашучыларны вактөяк чатаклыкларга, үзара үпкәләшүләргә игътибарны юнәлтеп, көчне юк-барга сарыф итмәскә өндәде. Алда торган Президент сайлаулары кампаниясе соң дәрәҗәдә кискен булачак, чөнки фон властьтагылар өчен уңай түгел. Власть, кешеләр Путинны яклап тавыш бирсен өчен, ныклап тырышачак. Әмма җәмгыять үзгәрешләр таләп итә, шуңа күрә дә икенче турның безнең лидер катнашында узачагы чынбарлыкка бик якын. Бу зур масштаблы бурыч, моның өчен безнең эш нәтиҗәләрен кимендә ике тапкыр арттырырга кирәк.

Чыгыш ясаучы А.В. Прокофьев сайлау кампаниясе барышындагы контрольлек итү эшләре турында сөйләде. Видеоконтроль булган урыннарда (бу бигрәк тә Мәскәүгә кагыла) КПРФ «Бердәм Россия»не җиңде. Безгә, видеоязма, участок номеры, участок сайлау комиссиясенең номерын күрсәтеп, картотека төзергә кирәк. Республикада булган тәртип бозулар язылган видеороликларның барысын да интернетка кую зарур. Бу үзенә күрә кисәтү чарасы булачак, чөнки закон боза торган участок сайлау комиссиясе членнары бу хакта хәбәрнең киң таралуыннан бик куркалар.

Пленумда тикшерелгән барлык мәсьәләләр буенча да тиешле карарлар кабул ителде.



**КПРФ Үзәк Комитеты члены, КПРФ рескомы беренче секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Гаязович МИРГАЛИМОВ котлавы**

***Кадерле иптәшләр!***

*2011 ел – Компартия өчен бик тә киеренке һәм җаваплы булган ел тарихка китеп бара. Йомгак ясап, ышаныч белән шуны әйтергә була, КПРФның Татарстан региональ бүлеге Россия Федерациясе Дәүләт Думасына депутатлар сайлау буенча коточкыч авыр сайлау кампаниясен намус белән үтте.*

*Алда торган ел да гади булмаячак. Март аенда ук инде безнең каршыда язмышыбызны хәл итә торган вакыйга – Россия Президентын сайлау бурычы тора. Коммунистлар, бердәм булып, бу постка үз лидерларын – Г.А. Зюгановны тәкъдим иттеләр. 2012 елның безнең өчен генә түгел, ә балаларыбыз, оныкларыбыз язмышы өчен дә хәлиткеч ел булуы бик ихтимал.*

*Яңа ел белән котлап, һәммәгезгә дә сәламәтлек, бәхет һәм иминлек, рухи ныклык, кыюлык һәм гражданлык активлыгы телибез!*

*Яңа елда өметләрегез аклансын, планнарыгыз тормышка ашсын!*

***Яңа ел белән, кадерле татарстанлылар!***

## В.П. Пешков – Госдума депутаты

Психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы, КПРФ Үзәк Комитеты Председателе киңәшчесе Виктор Петрович Пешков 2011 елның 4 декабрендә VI чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутат итеп сайланды. Ул 1995-2003 елларда II һәм III чакырылышларда да РФ депутаты иде. Шулай итеп, Госдумада соңгы 2 чакырылышта Татарстаннан бер генә КПРФ депутаты да булмаган булса, хәзер 2 депутатыбыз бар: В.П. Пешков һәм В.Н. Лихачёв.

КПРФтан депутатлыкка кандидатларның Чаллы төркемен җитәкләгән В.П. Пешков ноябрь аенда нефть төбәге районнарын йөреп чыкты. Сайлаучылар белән очрашуларның Азнакай шәһәрендәгесе аеруча җанлы узды. Мәскәү кунагы азнакайлыларның КПРФ партиясе белән кызыксынуы аеруча көчле булудан канәгать калды. Очрашуда катнашучы сайлаучыларның уртак фикерен белдереп, хезмәт ветераны, районның элеккеге ЗАГС бүлеге җитәкчесе



В. Пешков Азнакайда

булып эшләгән Лена Гыймаева, партия сафларында тормасак та, күңелебез белән без коммунистлар, дип белдерде. Ул шулай ук КПРФның эшчәнлегеннән канәгать булмавы, аны җанландырырга кирәклеген әйтте. Коммунистлар урынлы тәнкыйтьтән тиешле нәтиҗә ясадылар һәм кыска гына вакыт эчендә сайлаучыларны КПРФка тавыш бирүгә юнәлтә алдылар. Нәтиҗәдә Азнакай шәһәре республика буенча КПРФка тавыш бирүчеләрнең иң югары күрсәткечена ирешә. Бу хакта тулырак хәбәрләрне сез өченче биттән укый аласыз.

Бу хакта тулырак хәбәрләрне сез өченче биттән укый аласыз.

**5 майда «ПРАВДА» газетасына – 100 ел**

**Барлык почта бүлекләрендә дә «ПРАВДА» газетасына язылырга мөмкин. Газетаның индексы: 50102. Ярты елга язылу бәясе: 634,44 сум.**

# Районнар ничек тавыш бирде?

| Төбәк | Районнар | «ПРАВОЕ ДЕЛО» | «БЕРДӘМ РОССИЯ» | «ЯБЛОКО» | КПРФ | «ПАТРИОТЫ РОССИИ» | ЛДПР | «ГАДЕЛ РОССИЯ» |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәскәү төбәге | Алексеевск | 0.06% | 94.82% | 0.13% | 1.99% | 0.13% | 1.57% | 0.99% |
| | Әлки | 0.03% | 98.56% | 0.01% | 0.70% | 0.01% | 0.31% | 0.33% |
| | Апас | 0.06% | 98.07% | 0.09% | 0.69% | 0.03% | 0.22% | 0.31% |
| | Арча | 0.05% | 96.17% | 0.12% | 2.42% | 0.06% | 0.43% | 0.64% |
| | Әтнә | 0.07% | 97.53% | 0.20% | 1.01% | 0.05% | 0.25% | 0.59% |
| | Буа | 0.04% | 97.75% | 0.06% | 1.40% | 0.03% | 0.28% | 0.30% |
| | Буа шәһәре | 0.10% | 94.00% | 0.19% | 4.03% | 0.10% | 0.66% | 0.81% |
| | Югары Ослан | 0.16% | 82.74% | 0.44% | 6.22% | 0.22% | 3.81% | 2.97% |
| | Биектау | 0.15% | 89.48% | 0.42% | 4.70% | 0.17% | 1.32% | 3.21% |
| | Чүпрәле | 0.07% | 94.95% | 0.14% | 2.92% | 0.13% | 0.67% | 0.66% |
| | Яшел Үзән | 0.33% | 80.62% | 0.66% | 10.20% | 0.32% | 4.20% | 2.88% |
| | Яшел Үзән шәһәре | 0.21% | 75.64% | 1.32% | 13.19% | 0.28% | 4.82% | 3.57% |
| | Казан Киров районы | 0.55% | 65.08% | 1.84% | 13.98% | 0.60% | 7.60% | 9.08% |
| | Казан Мәскәү районы | 0.93% | 43.90% | 5.44% | 21.52% | 1.13% | 9.93% | 14.83% |
| | Кайбыч | 0.17% | 94.50% | 0.29% | 2.56% | 0.12% | 0.88% | 1.09% |
| | Кама Тамагы | 0.16% | 90.37% | 0.29% | 5.60% | 0.20% | 1.46% | 1.29% |
| | Лаеш | 0.13% | 92.20% | 0.51% | 3.18% | 0.14% | 1.47% | 1.92% |
| | Питрәч | 0.00% | 97.94% | 0.06% | 0.76% | 0.02% | 0.39% | 0.60% |
| | Спас | 0.08% | 93.65% | 0.16% | 3.66% | 0.09% | 0.81% | 1.16% |
| | Тәтеш | 0.35% | 77.24% | 0.75% | 12.97% | 0.35% | 3.60% | 3.90% |
| | Чистай | 0.13% | 88.04% | 0.21% | 7.26% | 0.19% | 1.65% | 2.03% |
| | Чистай шәһәре | 0.30% | 77.96% | 0.76% | 10.49% | 0.36% | 3.90% | 5.28% |
| Нефть төбәге | Азнакай | 0.34% | 80.66% | 0.63% | 9.95% | 0.36% | 2.85% | 3.65% |
| | Азнакай шәһәре | 0.41% | 59.73% | 1.32% | 24.86% | 0.53% | 4.57% | 6.45% |
| | Аксубай | 0.09% | 96.83% | 0.13% | 1.18% | 0.12% | 0.58% | 0.94% |
| | Әлмәт | 0.25% | 89.14% | 0.46% | 5.16% | 0.26% | 1.96% | 2.18% |
| | Әлмәт шәһәре | 0.29% | 80.88% | 0.49% | 11.70% | 0.38% | 2.74% | 2.64% |
| | Баулы | 0.14% | 91.47% | 0.20% | 4.51% | 0.18% | 1.99% | 1.09% |
| | Баулы шәһәре | 0.46% | 75.87% | 0.86% | 12.41% | 0.59% | 3.80% | 5.14% |
| | Бөгелмә | 0.19% | 86.19% | 0.44% | 7.15% | 0.22% | 2.64% | 2.65% |
| | Бөгелмә шәһәре | 0.36% | 75.45% | 0.72% | 14.63% | 0.47% | 3.78% | 3.90% |
| | Зәй | 0.02% | 97.46% | 0.06% | 1.44% | 0.01% | 0.55% | 0.38% |
| | Зәй шәһәре | 0.10% | 92.43% | 0.20% | 5.00% | 0.13% | 1.11% | 0.81% |
| | Лениногорск | 0.11% | 95.59% | 0.19% | 1.91% | 0.14% | 0.92% | 1.05% |
| | Лениногорск шәһәре | 0.26% | 82.45% | 0.63% | 9.22% | 0.41% | 2.79% | 3.20% |
| | Түбән Кама | 0.26% | 82.91% | 0.76% | 8.38% | 0.38% | 3.10% | 3.59% |
| | Түбән Кама шәһәре | 0.49% | 62.70% | 1.24% | 18.61% | 0.77% | 4.75% | 9.65% |
| | Яңа Чишмә | 0.09% | 96.62% | 0.17% | 1.29% | 0.02% | 0.87% | 0.75% |
| | Нурлат | 0.00% | 99.17% | 0.02% | 0.51% | 0.01% | 0.19% | 0.09% |
| | Нурлат шәһәре | 0.03% | 98.30% | 0.05% | 1.09% | 0.05% | 0.30% | 0.19% |
| | Сарман | 0.09% | 95.93% | 0.16% | 1.62% | 0.09% | 0.97% | 0.76% |
| | Чирмешән | 0.03% | 97.97% | 0.07% | 0.86% | 0.03% | 0.27% | 0.34% |
| | Ютазы | 0.12% | 95.51% | 0.24% | 2.21% | 0.18% | 0.66% | 0.65% |
| Үзәк төбәк | Казан Авиатөзелеш районы | 0.70% | 57.58% | 2.68% | 17.70% | 0.79% | 5.38% | 13.24% |
| | Казан Вахитов районы | 0.64% | 63.91% | 2.70% | 14.15% | 0.62% | 6.22% | 10.32% |
| | Казан Яңа Савин районы | 0.86% | 61.84% | 2.91% | 16.61% | 0.89% | 5.41% | 9.97% |
| | Казан Идел буе районы | 0.52% | 64.41% | 1.33% | 13.64% | 0.54% | 7.53% | 11.02% |
| | Казан Совет районы | 0.85% | 67.26% | 2.44% | 11.93% | 1.03% | 5.60% | 9.59% |
| Чаллы төбәге | Әгерже | 0.21% | 91.06% | 0.33% | 4.17% | 0.24% | 2.36% | 1.25% |
| | Актаныш | 0.08% | 95.33% | 0.14% | 3.07% | 0.10% | 0.57% | 0.49% |
| | Балтач | 0.17% | 92.15% | 0.43% | 3.81% | 0.26% | 1.42% | 1.44% |
| | Алабуга | 0.00% | 95.04% | 0.06% | 4.12% | 0.02% | 0.39% | 0.28% |
| | Алабуга шәһәре | 0.28% | 77.68% | 0.68% | 12.20% | 0.36% | 3.33% | 4.68% |
| | Кукмара | 0.08% | 93.85% | 0.21% | 3.84% | 0.12% | 0.78% | 0.88% |
| | Мамадыш | 0.17% | 93.86% | 0.17% | 2.64% | 0.15% | 1.63% | 1.24% |
| | Менделеевск | 0.12% | 87.23% | 0.35% | 8.35% | 0.23% | 1.73% | 1.53% |
| | Минзәлә | 0.07% | 95.26% | 0.29% | 1.97% | 0.09% | 1.32% | 0.92% |
| | Мөслим | 0.15% | 97.05% | 0.13% | 1.39% | 0.10% | 0.41% | 0.70% |
| | Чаллы Автозавод районы | 0.52% | 68.18% | 1.06% | 16.58% | 0.55% | 3.77% | 8.32% |
| | Чаллы Комсомол районы | 0.46% | 65.98% | 1.21% | 18.74% | 0.43% | 4.34% | 7.59% |
| | Чаллы Үзәк районы | 0.61% | 64.86% | 1.15% | 19.66% | 0.60% | 4.08% | 7.88% |
| | Балык Бистәсе | 0.15% | 95.41% | 0.18% | 2.11% | 0.17% | 0.72% | 0.89% |
| | Саба | 0.22% | 94.74% | 0.35% | 2.50% | 0.26% | 0.98% | 0.91% |
| | Тукай | 0.15% | 92.81% | 0.29% | 4.14% | 0.13% | 1.05% | 1.16% |
| | Теләче | 0.05% | 98.02% | 0.09% | 0.84% | 0.08% | 0.41% | 0.26% |

Мәгълүматлар tatarstan.izbirkom.ru сайтыннан алынды

## Дуслык элемтәләре: Төньяк Кавказ

# Тугандаш Кабардино-Балкариядә




**Рәсемдә сулдан уңга: М. Битокова, Җ. Мисиров, З. Шихалиева һәм Х. Гыйләҗев.**

Декабрь ахырында берничә көн Нальчик шәһәрендә КПРФның Кабардино-Балкария республика комитеты эше белән танышырга туры килде. Ресvolkom шәһәрнең үзәгендә, Ленин урамында, Республика Парламенты белән янәшәдәге КБРның Информацион коммуникацияләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм яшьләр эше буенча министрлык бинасында урнашкан.

Республикада 860 меңгә якын кеше яши, 2200ләп коммунистлары бар. Алардан үрнәк алырлык нәрсәләр күп. Мисал өчен, республика буенча «Правда» газетасын алучылар саны 485кә җитә. Мәктәп балалары арасында 8600 пионер бар. Комсомоллар да актив эшли. 23 декабрьдә Кабардино-Балкар дәүләт университетының химия факультетында укучы 22 студентның партиягә кабул ителүе турында газетада хәбәр бирелгән.

Республика Парламентында 72 депутат бар, 6 депутаттан торган КПРФ фракциясе эшли. Республика Парламенты һәм Хөкүмәте газетасы иске исемен үзгәртеп тормаган, ул «Кабардино-Балкарская правда» дип атала. Анда даими төстә социализм чорындагы казанышлар турында горурланып язалар. 30 декабрьдә әлеге газетада «Храните добрые традиции» исеме белән минем интервью да басылды. Фоторәсем белән 1-2нче битләрдә бирелгән әлеге интервьюда мондый юллар бар:

Здесь не встретишь пьяных на улицах, люди вежливо относятся друг к другу, в общественном транспорте пассажиры уступают место старшим. Добрые традиции сохранены не только на бытовом уровне, но и в государственно-общественном секторе. За время пребывания в вашей республике я интересовался местной прессой, читал «Кабардино-Балкарскую правду» и заметил, что в этой газете регулярно публикуются материалы о Героях Советского Союза, Героях Социалистического Труда и других выдающихся людях, внесших большой личный вклад в становление и развитие нашей страны.

Төньяк Кавказның әлеге республикасында 4 декабрьдәге сайлау нәтиҗәләре дә куанычлы: КПРФка 17,63% тавыш бирелгән (Россия буенча бу күрсәткеч – 19,19%, Татарстанда – 10,59%). Көрәш кискен шартларда барган. Мисал өчен, Нальчик шәһәренең 127нче сайлау участогында сайлауга килүчеләргә бары тик 44 бюллетень бирелгән, шул ук вакытта өйләргә барып сайлату саны 486га җитә. Моңа кем ышансын? Сайлау законнары тупас бозылганы ярылып ята. Бу хакта КПРФ рескомы органы булган «За нашу Кабардино-Балкарию!» газетасы 29 декабрь санында яза.

Эшлекле очрашуларда КПРФның Кабардино-Балкария рескомы беренче секретаре, КБР Парламентында КПРФ фракциясе җитәкчесе Зәйрат Шихалиева, КПРФның Нальчик шәһәр комитеты секретаре Җамал Мисиров, КПРФ рескомы газетасы редакторы Мария Битокова һәм бюро әгъзалары катнашты. Алар Татарстан коммунистларына кайнар сәламнәрен юлладылар һәм Яңа ел котлаулары белән озатып калдылар.

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**РФ журналистлар союзы члены, «Татарстан коммунисты» газетасының баш редакторы, КПРФның Татарстан рескомы члены, Азнакай шәһәр комитеты беренче секретаре.**



# АЗНАКАЙДА САЙЛЫЙ БЕЛӘЛӘР...

## Гадел сайлаулар өчен!



РФ Дәүләт Думасына узган сайлауларда Азнакай районы һәм шәһәрендә яше-карты гадел сайлаулар өчен көрәшкә күтәрелде. Районның Мәнәвез авылындагы 541нче сайлау участогында КПРФтан хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия булып, һөнәре буенча инглиз теле укытучысы Резидә Галимова эшләде. Шунда ук күзәтүче булып партия, сугыш һәм хезмәт ветераны, 1970-80 елларда Азнакай райисполкомы председатele урынбасары булып эшләгән Мөбәрак Гәрәевич Хәсәншин катнашты. Нәтиҗәләр дә куанычлы: КПРФка 32,08%!

Фоторәсемдә әлеге участок эше белән кызыксынып килгән Азнакай шәһәр советы депутаты, комсомолның шәһәр комитеты беренче секретаре Рөстәм Сәләхов аларны ирешкән уңышлары белән котлый.

**Риф СӘЙФУЛЛИН,**
**Азнакай район территориаль сайлау комиссиясе члены.**

## Саннар һәм фактлар

Территориаль сайлау комиссияләре 5 еллык срокка оештырыла. Әмма Азнакайда бу срокны тутыра алмаучылар күп. 2010–2012 еллардагы сайлауларда Азнакай район территориаль сайлау комиссиясе председательләре булып бер-бер артлы чираттлашып З.А. Хужин, Д.З. Рәхмәтуллин һәм Л.М. Әхмәдишиналар эшләде. Шул ук чорда шәһәр территориаль сайлау комиссиясенең дә 3 председателе бер-берсен алыштырып тордылар.

КПРФтан Азнакай район территориаль сайлау комиссиясе члены булып дистә еллар буе эшләгән 72 яшьлек Риф Сәйфуллин 2011 елда Татарстан Үзәк сайлау комиссиясенең Почет грамотасы белән бүләкләнде. Ветеран яшь чагында ВЛКСМның Азнакай райкомы беренче секретаре була, аннан соң күп еллар буе районның баш ветеринария врачы булып эшли.

Татарстанда 2008 елның мартында Россия Федерациясе президентын сайлауларда тавыш бирү нәтиҗәләрен ф а л ь с и ф и к а ц и я л ә ү д ә гаепләнгән 59 яшьлек Илгизә Сираевага карата хөкем карары чыгарылды. РФ Генераль прокуратурасы сайтында хәбәр ителгәнчә, Азнакай районы №2 суд участогы мировой судьясы карары нигезендә Сираева гаепле дип табылды һәм штраф формасында хөкемгә тартылды.

Азнакай шәһәрендә яшәүче Гүзәлия Шакирова 4 декабрьдә узачак 512нче сайлау участогына комиссия члены итеп билгеләнә. Сайлау көнне иртәнге сәгать җиедедә ул эшкә юл тота. Тик тиешле урынга барып җитә алмый, Ленин һәм Нефтьчеләр урамы чатында аны «Дэу-Матиз» машинасы бәрдерә. Аяклары, ядәч сөяге сынган, күкрәк читлеге, эче бик нык җәрәхәтләнгән ханымны ашыгыч рәвештә район үзәк хастаханәсенә китерәләр. Табиблар шундук ярдәмгә ашыга. 45 яшьлек өч бала анасының гомерен саклап калу өчен барын да эшлиләр. Тик шул ук көнне икенче операция вакытында зыян күрүче мәңгегә күзләрен йома.

Ул вафат булган көнне Мәскәүдә аны бер минутлык тынлык белән искә алдылар, Россия Үзәк сайлау комиссиясе председателе Владимир Чуров, балаларына булышам, дип вәгъдә иткән.

2011 елның 4 декабрендә Россия Дәүләт Думасы сайлау нәтиҗәләре буенча КПРФка тавыш бирүчеләр проценты белән Азнакай шәһәре республикада беренче урынга чыкты: әлеге күрсәткеч – 24,86%. Шәһәрдәге 20 участокның 6сында КПРФны яклаучылар 31-35%ка җитә.

## «Сарыкмы без, әллә кешеләрме?»

**4 декабрьдә узган РФ Дәүләт Думасына сайлауларда Азнакай шәһәрендә кечкенә генә революция булды — бирердә КПРФ рәсми рәвештә 25% тавыш җыйды! (Республика буенча 10,59%, ә күп татар районнарында 0,2-3% кына дип игълан ителде бит.)**

**КПРФ фиркасенең район комитеты икенче сәркатибе, Азнакай шәһәре советы депутаты, машина йөртүче булып эшләүче Рәшит САФИУЛЛИН, гадел узса, бүтән районнарда да сайлау нәтиҗәләре башкача булыр иде, дип исәпли.**

**— Рәшит абый, Азнакайда сайлаулар ничек үтте?**

— Халык сайлауга катнашты, «явка» 60%ка якын.

Бу сайлауда зур хәрәмләшүләр булачагы алдан ук билгеле иде. Барысы да «Бердәм Русия» җиңәчәген белде, ләкин фикерли алган халык махсус аларга каршы тавыш бирергә дип барды. Ягъни нинди фирка каршында тамга кую мөһим түгел, «Бердәм Русия» генә булмасын.

Азнакай шәһәрендә КПРФ 25% тавыш җыйды, ә район буенча бу сан 10% тәшкил итә, Әлеге күрсәткеч Татарстан буенча иң зурысы. Бу безнең өчен кечкенә булса да җиңү.

**— Ни рәвешле бу кадәр тавыш җыя алдыгыз? Хакимият комачауламадымы? Мәсәлән, Нурлатта 99% кеше сайлауга барган һәм шуларның барысы да диярлек «Бердәм Русия» өчен тавыш биргән.**

— Азнакай халкы Татарстан буенча протест күрсәткән бердәнбер шәһәр булып чыкты һәм моның белән горурланам. Бу сайлауга җитди әзерләндек, күзәтүчеләребезне булдырдык. Шәһәрнең үзендә 20 сайлау участогы оештырылды, барысына да күзәтүче куйдык, бездән «решающий голос»ы булганнар да комиссиядә эшләде. ЛДПР белән дә килешкән идек, ләкин соңыннан алар «Без бу эштә катнашмыйбыз» дип артка чигенде. Район буенча 5 күзәтүче билгеләнде, тик авылларга өмет юк, алар куркытылган, изелгән. Авыллардагы сайлаулар белән комиссия рәисе түгел, ә шундагы авыл советы кешеләре идарә итә. Сайлау комиссиясе әгъзалары аларга буйсына, алар ни әйтә, шуны эшлиләр.

Аннары авылларга күзәтүчеләрне махсус куймадык, сайлау нәтиҗәләре ярылып ятсын дип теләдек. Чыннан да, без фаразлаганча килеп чыкты. Күзәтүчеләребез эшләгән авылларда КПРФка тавыш бирүчеләр хәтта 30%ка кадәр җиткән, ә без булмаган җирдә бу сан 1-2%тан артмады. Махсус тикшерү дә уздырырга кирәкми, кайда алданганнары, хәрәмләшкәннәре процентлардан күренеп тора. Гадел сайлаулар узган участокта хакимият фиркасе тиешле тавыш җыя алмады.

Азнакайның үзендә дә дүрт сайлау участогында КПРФ күрсәткечләре түбән, чөнки күзәтүчеләргә басым булды. Хакимият ул якка оста, төрле ысуллар таба белә. Кирәк булса, бөтен нәселеңне тикшереп чыгып басым ясаячак. Якыннары, балалары авыр хәлдә икән, хакимияттәгеләр алар белән сатулаша башлый. Сайлау нәтиҗәләре безнеңчә булса, ярдәм итәбез дип вәгъдә бирәләр. Кеше кая барсын, аның үз хәле хәл! Мәнә безнең дүрт күзәтүчебезгә дә шул рәвешле басым ясалды һәм тавышларны югалттык. Болай безнең күрсәткеч 30%тан артык булыр иде дип уйлыйм.

«Бердәм Русия» агитациясе каты барды. Пенсионерларга «Бердәм Русия» сайланмаса, сугыш башланачак, балаларыгыз сугышка җибәреләчәк, пенсия түләнмәячәк», дип сөйләп, алдап йөрергә дә оялмадылар. Узган елгы сайлаулар вакытында хакимият куштаннары: «КПРФка ничек тавыш бирәсез? Аларның тишек ыштаны да юк. Кар басып китсә, юлларыгызны кем чистартыр? КПРФның сезне күмәргә көрәге дә юк»,—дип аңлатып йөрде. Куштаннар шәп эшли. Әби-чәби каршы дәшми, сугыш кына булмасын дип тели.

**— Интернетка күз салсаң, анда төрле фальсификацияне фаш иткән язмалар да, видеотасмалар да күп. Сайлау тартмаларына алдан тавыш бирелгән йөзләгән данә бюллетень салалар, махсус кешеләрне автобусларга утыртып, ялган «о т к р е п и т е л ь н ы й » л а р белән тавыш бирдертәләр, сайлау кабиналарында кәгазьдә карасы бетә торган каләмнәр дә кулланганнар һ.б. Барысын да күзәтүчеләр теркәп барган, интернетка салган. Сездә хәрәмләшү очраклары булдымы?**

— Азнакайда да галәмәтләр күп булды. Урсай авылында КПРФ күзәтүчесен кертмәделәр, сайлау башланыр алдыннан куып чыгардылар. Имеш, юлламасында дөрес номер куелмаган, ләкин аның участокка кереп утырырлык барлык документлары тәртиптә булды.

Урсайда участокка килә алмаганнар янына күчереп йөртелә торган тартма белән мәш килделәр. Авылның яртысын үткәннәрдерме, ул тулган. 148 бюллетень чыккан, барысы да «Бердәм Русия»гә тавыш биргән. 148 кешене сайлату, һәрбер өйгә керү өчен берничә сәгать кирәк, әле ул чакта ашарга да, ял итәргә дә туктамаганнар булып чыга. Ә бу бик тиз вакыт эчендә эшләнгән.


Мәнәвез авылында безнең фиркадән дә сайлау комиссиясе әгъзасы булды, шул бер кызыклы очракны сөйләде. Бу күпчелек җирдә шундый хәл дип уйлыйм, сайлау көнендә район башлыгы һәрбер сайлау участогын йөреп чыга, имеш, сайлауны күзәтеп тикшерергә дип, сайлаучыларны белешә. Чыннан да тиешле партиягә тавыш бирү ничегрәк барганын күзәтә. Үзе йөреп чыккач, урынбасарлары район буйлап тагын бер кат әйләнә. Шуңа өстәп, һәрбер сайлау участогында хакимияттән куелган җаваплы кеше була. Бу юлы да матур гадәтен дәвам итеп, Азнакай район башлыгы Мәнәвез авылының сайлау участогына килгән. КПРФтан булган күзәтүче аңа: «Нишләп йөрисез, монда сайлау комиссиясе рәисе бар, ул барысы өчен дә җавап тота!» — дип кисәткән, һәм дөрес эшләгән! Район башлыклары эше түгел ул.

**— Мартта Русия президентын сайлаулар булачак. Алар гадел узсын өчен нишләргә кирәк? Гомумән, гадел сайлаулар була аламы?**


Нишләп булмасын? Бар, Азнакайда КПРФның 25% тавыш җыюы шуның ачык мисалы. Безнең халыкның төп ялгышы — сайлауга йөрмәү, битараф калу. Сайлауга ник бармыйсың дип сорасаң, «Мин политик түгел», диләр. Бу нинди хәл инде? Бу илдә яшибез бит, тәртип һәм канунның өстен булуы безгә кирәк. Сарыкмы без, әллә кешеләрме? Аз гына башны эшләтеп яшәргә кирәк, сарык көтүе генә уйламыйча йөри ала.

Халык үзе тормышын үзгәртергә теләми икән, берәү дә аның өчен тырышмаячак. Башны җүләргә салып йөрү җиңел ул, ләкин намус, гражданлык позициясе, үз сүзеңне, фикереңне әйтү дигән төшенчәләр дә бар. Иртәгәсен дә уйларга кирәк.

**Римма БИКМӨХӘММӘТОВА.**
(«Ирек мәйданы», 16.12.2011 ел, 3 бит.)



Азнакай күренешләре


«Восток» кинотеатры

## Азнакай районы башлыгы Р. Галиев үз вәкаләтләрен өстеннән төшерде

**(Казан, 20 декабрь, «Татар-информ»).** Ютазы районының элеккеге башлыгы Марсель Шәйдуллин Татарстанның Азнакай районына эшкә күчә.

Бүген Ютазы район Советы утырышы (анда Марсель Шәйдуллин Ютазы районы башлыгы вәкаләтләрен өстеннән төшерде) тәгәлләнгәннән соң, Азнакай район һәм шәһәр советларының берләштерелгән утырышы узды. Утырышта Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков катнашты.

Азнакай районы башлыгы Рафис Галиев үз вәкаләтләрен өстеннән төшерде. Депутатлар аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуны яклап тавыш бирде. Илдар Зиннуров та үз теләге белән район башкарма комитеты җитәкчесе вазыфасыннан китте.

Утырышта Марсель Шәйдуллинга район башкарма комитеты җитәкчесе вазыфаларын башкару эше йөкләнүе турында карар кабул ителде. Бу хакта район советының матбугат хезмәте хәбәр итә.

# Пресс-конференция: ел йомгаклары

**КПРФның Республика комитетында VI чакырылыш Дәүләт Думасы депутатлары В.Н. Лихачёв һәм В.П. Пешков катнашында коммунистларның йомгаклау пресс-конференциясе узды.**

Пресс-конференцияне ачып, рескомның беренче секретаре **Х.Г. Миргалимов** республика партия оешмасы эшчәнлегенә һәм ТР Дәүләт Советының КПРФ фракциясе эшенә йомгак ясады. Ул шулай ук КПРФның XIV съезды, Г.А. Зюгановның РФ Президенты постына кандидатлыкка тәкъдим ителүе һәм реском пленумы уздырылуы турында сөйләде.

– Россиядә хәзер хәлләр бер дә гади түгел, – дип ассызыклады чыгыш ясаучы. – Соңгы 10-15 елда зур шәһәрләрдә беренче тапкыр шундый киң күләмле митинглар уза. Кешеләрнең протест белдерүе, мондый кәефе аңлашыла. Сайлауларны гадел итеп уздыруны, Үзәк сайлау комиссиясен, башында торган Чуров белән бергә, отставкага җибәрүне таләп итүләр нәкъ менә КПРФ тарафыннан тәкъдим ителгән иде. Тик ул митингларда Кудрин ише әфәнделәрнең ни өчен катнашуы гына аңлашылып җитми.

29 декабрьдә Татарстан Дәүләт Советының КПРФ фракциясе, – диде Х.Г. Миргалимов, – республикадагы сайлаулар нәтиҗәләре буенча үзенең политик белдерүен игълан итәчәк.

**В.Н. Лихачёв,** РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Вакыт партиябезнең сайлауларга карата кабул иткән программасының киң социаль яклау тапканлыгын күрсәтте. Коммунистлар – үз эшен гаделлек һәм дөреслек принципларында алып бара торган конструктив оппозиция ул.

КПРФ депутатлары – айсберглар түгел! Безгә Татарстаннан сайланган депутат-коммунистларның республика җитәкчелеге белән хезмәттәшлек итү формаларын эшләргә кирәк.

Татарстанның электораты актив. Мин Мәскәүгә 70тән артык турыдан-туры мөрәҗәгать алып китәм, алар – оборона комплексын яклауга, экологик хәлне, бигрәк тә республикабызның нефть чыга торган районнарындагы вәзгыятьне яхшыртуга, академик фәнгә һәм яшьләргә ярдәм итүгә кагыла торган тәкъдимнәр.

**В.П. Пешков,** РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Коммунистлар тәкъдим иткән программалар кеше тормышының һәм эшчәнлегенең бар ягын да колачлый.

КПРФ вәкиле Г.А. Зюгановны Россия Федерациясе Президенты итеп сайласак, без дәүләттә бара торган процессларга йогынтыбызны көчәйтә һәм арттыра алабыз. Тәҗрибә, ихтыяр көче, чыдамлык – менә нинди сыйфатлар хас бу кешегә. Заман таләпләре аның холык-фигыленә һәм сыйфатларына тәңгәл килә. Геннадий Андреевич – көчле шәхес. Иң мөһиме, сайлау процессындагы барлык кешеләр дә закон каршында тигез булсыннар иде, әмма моның өчен инде гамәлдә булган нормаларны үзгәртү кирәк, – диде В.П. Пешков.

**А.В. Прокофьев,** ТР Дәүләт Советы депутаты:

– Президент сайлаулары буенча март кампаниясе техник характерда гына булмаячак. Моның шулай икәнлеге бүгеннән үк билгеле. Гражданнарда контрольдә катнашу ихтыяҗы зур: урналарга бюллетеньнәрне салып китү генә түгел, һәрбер тавышны саклап калу да мөһим.

Кешеләр Президент итеп «Бердәм Россия» вәкилен сайлауга каршы булып, берләшәләр, алга таба политик консенсуска килергә – уртак килешү юлын табарга кирәк булачак.

Җәмәгатьчелек сайлауларны уздыру законнарын торгызуны таләп итәләр. Власть бу ситуациядә аларга таба үзе адым ясарга тиеш, – дип ассызыклады А.В. Прокофьев.

**Илшат ВӘЛИУЛЛИН,**
КПРФның Казан шәһәре Киров райкомы беренче секретаре.

# Мең ярым кеше ризасызлык белдерде

24 декабрь Казанның Ярминкә мәйданында урам җыены узды. Митингның төп шигаре – «Гадел сайлаулар өчен!» иде. Җыенда мең ярымга якын кеше катнашты.

Урам җыены уза торган урын тимер рәшәткәләр белән уратып алынган иде. Халыкны электрон капкалар аша керттеләр, «нинди плакатларыгыз бар?» дип кызыксынып, букчаларны тикшерделәр. Цирк янында, стадион тирәли полициянең ике дистәгә якын йөк машиналары торды. Полиция хезмәткәрләре үзләрен бик итагатьле тотты, дорфалык сизелмәде.

Митингның төп оештыручылары – Коммунистлар фиркасенең Вахитов районы бүлеге рәисе Игорь Веселов һәм «Яблоко» фиркасе әгъзасы Айрат Гыйбадуллин. Аларга «Урыс мәдәнияте оешмасы» да кушылган. ЛДПР бу эштә катнашмаячагын белдергән. Урам җыены Казан хакимияте тарафыннан рөхсәт ителде, хәтта электр чыбыгын сузарга да түрәләр ярдәм иткән дигән сүзләр булды.

Шигарьләр арасында Татарстанның сайлау комитеты рәисе Анатолий Фоминны эштән бушатуны таләп иткән «Фомин, уйди в отставку!», «Не признаем результаты выборов», «Миңнеханов, ждем обещанного диалога» дигәннәре бар иде.

Мәйданга «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе рәисе Илшат Әминов та килде. Мәйданда үзенең сайлауларга ризасызлыгын белдерер өчен Галиәскәр Камал исемендәге татар дәүләт академия драма театры директоры Шамил Закиров та килде. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Равил Шәрәфиев та халык белән бергә иде.

«Бу сайлаулар, андагы хәрәмләшүләр, илдәге ыгы-зыгы мине бик борчый. Илдә безнең бөтен ирегебезне, тавышларыбызны тартып алдылар. Мәйданга мин үземнең карашымны белдерергә дип килдем», диде Шамил Закиров.

Урам җыены 15.10 сәгатьтә башланды, Беренче булып сүз Игорь Веселовка бирелде. «Киләсе сайлауларга әзер булырга тиешбез, безгә бәйсез күзәтүчеләр кирәк! Фомин китәргә, вәзгыять үзгәрергә тиеш. Фальсификация – җинаять. Бу пычрак эштә меңләгән укытучылар, табибларны катнашырга мәҗбүр иттеләр. Татарстанның сайлау рәсмиләре оятсыз рәвештә хәрәмләштеләр, ә Татарстанның прокуратурасы, тикшерү комитеты боларның барысына да күз йома, җавапка тартмыйлар. Прокурор Кафил Әмировны да, Николаевны да отставкага!» дип чыгыш ясады. Аның чыгышын алкышлар белән куәтләделәр.

КПРФ әгъзасы Нәсимә Столярова: «Без сайлаулар нәтиҗәләре белән риза түгел! Хөкемдарлар алышынырга тиеш, алар да бу хакимиятнең ялган системасында катнашалар. Совет заманында хөкемдарлар халык алдында хисап ясый иде. Хөкем системасын үзгәртергә! Русиядә мәгариф, медицина түләүлегә әйләнде, нефтьне генә суырып яталар. Власть халыкка хезмәт итәргә тиеш. Депутатлар, республика башлыклары, федерация сенаторлары сайланырга тиеш! Демократик институтларны кайтаруны таләп итәбез!» дигән сүзләр әйтте. Мәйдандагы халык аны хуплап «Перевыборы!» дип кычкырды.

Социология белгече Владимир Беляев: «Халыкны талау кайчан туктар? Ник авыл халкын изеп, куркытып, тапкан малын тартып алып, аларны мыскыл итәләр? Сөтне 5 сумга сатып алалар, ә үзләре 10 тапкырга кыйммәткә сатып, үз кесәләрен тутыралар. Оятсыз хакимият!», – диде.

**Римма БИКМӨХӘММӘТОВА.**
«Азатлык» радиосы. 24.12.2011.

# БЕРДӘМ БУЛЫЙК!

Рәсәй илендә шушы елның 4 мартында булачак Президент сайлауларында җиңеп чыгу өчен котырынып көрәш башланды. Хәтта, моңа кадәр киләчәккә өметләрен өзгән һәм көрәшүләренең нәтиҗәсе күренмәгән вак партияләр дә бераз уянып, айнып китеп бу политик чарада тагын бер тапкыр үзләрен күрсәтеп алырга булдылар. 20 ел эчендә иле, халкы алдында телгә алып уңай бәя бирердәй бер эш тә майтара алмаган «Бердәм Россия» олигархлар партиясе аяклары астындагы тайгаклык ныграк шуа башлавын, гади халык алдындагы болай да булмаган абруйларының нык какшавын, аларга тәмам ышаныч бетүен чамалап нинди генә астыртын, халык аңын томалау юлларына басмыйлар.

«Татарстан коммунисты» газетасының 2011 ел 25 октябрь санында бастырылган Артем Прокофьевның: «Бүген компартия чын-чынлап җиңеп чыга ала» дигән сүзләрендә чынбарлык зур. Фәкать КПРФ кына, бүгенге көндә, Рәсәй экономикасының, урта һәм хәерче хәлендәге ил халкының авыр тормышын аңлый белүче һәм армый-талмый шуны үзгәртү, яхшырту өчен көрәшүче һәм җимереклектән чыгарга дәлилле перспектив планнарын төзүче партия буларак сайлауларда җиңеп чыгарга сәләтле. Бу катлаулы эшләрне башкарып чыгу өчен компартия җитәкчеләренең генә активлыгы җитми. Моның өчен әлеккеге һәр рядовой коммунист әле аягында йөри алса, халык арасында булырга һәм зур аңлату эшләре алып барырга һәм нигезле кыю чыгышлар ясап, идарә итүче партияне фаш итүдә актив катнашырга тиешләр.

Карагызчы, теле-радио тапшыруларында «Бердәм Россия» җитәкчеләре нинди вәгъдәләр белән халыкның башын әйләндерәләр, бигрәк тә студентлар арасында көчле пропаганда алып барыла. Алар белән кара каршы утырып сөйләшкән, әңгәмә корган кебек кыланалар, үзләрен гади итеп күрсәткән булалар. Әгәр, хәтта, вак-төяк оешмаларның да җитәкчеләре хезмәткәрләренең «БР» файдасына сайлауны тәэмин итми икән, ул эшеннән алып атылачак. Янаулар басымы астында узган сайлауларның нәтиҗәсе дөрес, гадел булырга мөмкинме соң? Юк, әлбәттә.

Ил халкы ничә чакырылыш депутатларның коры куык вәгъдәләреннән, ялганнарыннан тәмам гарык булып арыды, «Бердәм Россия»гә ышанмый башлады. Куркыныч нәтиҗәләр булмасын өчен һәр коммунист халык арасында киң аңлату эшләре алып барсын иде. Бер тиенгә алданып, сатылып ялган процентларны җыюда катнашкан укытучылар да халык алдында үз абруйларын югалтты һәм аларга ләгънәтләр яудырылды.

Әйе, халык хәзер кемнең кем икәнлеген аңлый башлады. 20 ел алдауга көйләнгән тормышның кая баруын, илнең бонкротка әйләнә баруын яшь буын да аңлый башлады, шуңа күрә алар бүген коммунистлар идеологиясен яклыйлар. Без коммунистлар һәм ветераннарның бурычы – үзебезнең балаларыбызга, оныкларыбызга, тирә ягыбызда яшәүчеләргә хакыйкатьне ныклап аңлату. Безнең курс – сайлауларда җиңеп чыгу!

**Рубис ЗАРИПОВ,**
партия һәм хезмәт ветераны. Чаллы.

*Укучыларыбыз иҗаты*

## Хакыйкатькә сәяхәт

Сәер. Адаштык без... Күпмегәдер?..
Тәгәрибез тирән упкынга...
Юлны белгәннәргә тик юк ирек,
Имеш илбаш белә – ул гына.

Бүген ил башында кемнәр алар?
Гел алдыйлар, халык мескенне...
Сайлау дигән булып кыланалар,
Нәтиҗәсе? Һаман бертөрле.

Менә әрәм, ничә еллар инде
Ил язмышы белән уйныйлар.
Халык уе белән исәпләшми,
Шулай яшәрбез, дип уйлыйлар.

Яшәү чыганагы – эштән мәхрүм
Таза ир-ат, эшлим диюче.
Җимерделәр барын, ләкин кайда
Кылганнарга җавап бирүче?

Каракларга күчте ил байлыгы,
Әкияттә булмас хикмәттер?
Җир йөзендә төрле хәлләр булган,
Безнең илдәгесе – сирәктер...

«Булдырабыз!» – диеп мактаналар
Артка табан чүгеп барганны.
Алар имеш дөрес, бар да дөрес –
Дөрес диләр чеп-чи ялганны.

Аңлашылмый, нинди акыл белән
Тырышалар акыл сатарга?
Өйрәтәләр «Русь»ны Ауропача
Ничек торып, ничек ятарга.

Хөррият дип, алдап үзгәртүләр
Җимерә бит илнең нигезен.
Чын аң, намус, әхлак таркалуы –
Шулмы җәмгыятебез безнең?

Сөенү-көенү, шатлык-кайгы
Бергә була алмый ничек тә!
Сораулар күп, җаваплар юк –
Әллә җәмгыять соңгы чиктә?..

Куып кертеп, сатлык, куркакларны
Көндәм көтү ясау – теләге.
Сизенәләр: нигезләре – черек,
Имеш булыр илнең терәге.

Бүген исән ветераннарны да,
Ансат кына сатып алмакчы...
Алар бердәм,утны-суны кичкән –
Чамалыйлар салган «кармак»ны...

Капчык-капчык имза җыйган булып,
Бар эшләре һаман алдауда.
Алдап узды Дума сайлауларын...
Депутатлык кирәк аларга!

Фиркаләрне берләштергән булып,
Алдыбызда уен уйныйлар.
Сайлаучының башын әйләндерү...
Татлы хакимлектән туймыйлар.

Яна, бата, егылалар бар да...
Үлем өермәсе – тәкъдирдә.
Сәбәбе бер – җитди идарәдә
Юлны бирмәү лаек хакимгә.

Сайлаучылар нишли? Алданалар!
Бит күбесе һаман ышана.
Юкса аерырга буладыр бит –
Кемнәр гадел, кемнәр «шпана»?

Ялтыравык вәгъдәләрдә түгел,
Бөтен хикмәт – кылган гамәлдә.
Ватаныбыз кабат алга атлар,
Дөрес юлга кайтсак әгәр дә!

Һәр тарафта акылсыз алымнар,
Ел саен – файдасыз адымнар.
Һичбер шик юк, ләгънәтен укырлар
Үзләре калдырган буыннар...

**Фердинанд ШАКИРОВ. Арча.**

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Наталья КОШКИНА
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420021, Казан шәһәре,
Сулъяк Болак урамы, 56. Тел./факс: (843) 292-53-26, 292-27-22.
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 30.12.2011 ел, 16.00, кул куелды – 16.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 44. Тираж 20000.
Бәясе ирекле.